**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.17 йорт, Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.aktanysh @tatar. ru,www.aktanysh.tatarstan.r

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
10.04.2020

КАРАР
№ ПР-70

**Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елга Актаныш муниципаль районы муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2019 елның 1 ноябрендәге ПР-255 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының «Ата-аналар түләвен исәпләү турында» 2020 елның 19 мартындагы 3419/20 номерлы хатын үтәп, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында ата-аналар түләвен исәпләгәндә төзәтмә коэффициентларын куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2020 елның 13 мартындагы 03-15/1859 номерлы хаты, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Россия Федерациясе 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2019 елның 07 февралендәге 546 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елга Актаныш муниципаль районы муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2019 елның 1 ноябрендәге ПР-255 номерлы карарының 1 пунктындагы дүртенче абзацына, яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

- "балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләве күләменә кучү чорына төзәтмәләр коэффициенты. 2020 елның 1 гыйнварына кадәр мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кабул ителгән балага - 2 айдан 3 яшькә кадәрге балалар өчен - 0,85, 3 яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганчыга кадәр – 0,865.

2. Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларын финанслау нормативлары нигезендә, мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Районның рәсми сайтында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында мәгълүмат-

телекоммуникация Интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Үзгәрешләр әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм үз көченә кергәнче барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә - 01.04.2020 елдан башлап кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче И.И.Габдулхаев